БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ
ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның июленнән бирле чыга. | №27 (7044) | 3 март, 1990 ел. ШИМБӘ | Бәясе 3 тиен.

**Иртәгә, 4 март— РСФСР, ТАССР һәм җирле Советларга сайлаулар көне.**

**Дәүләт власте органнарына үзгәртеп коруларның алгы сызыгында атларга сәләтле, иң лаеклыларны сайлыйк! Барыгыз да сайлауларга!**

КПСС РАЙКОМЫ БЮРОСЫНДА

## Сайлауларны оешканлык белән үткәрергә

КПСС райкомы бюросының чираттагы утырышында Мичурин исемендәге колхоз партия комитетының һәм халык депутатларының Урта Камышлы авыл Советы башкарма комитетының республикаларга, җирле Советларга сайлауларга хәзерләнү һәм үткәрү мәсьәләсен тикшерде.

Утырышта башлангыч партия оешмасының һәм авыл Советы башкарма комитетының РСФСР, ТАССР һәм җирле Советларга халык депутатларын сайлауларга хәзерләү һәм аны оешканлык белән үткәрү буенча билгеле оештыру һәм масса-политик эш алып баруы күрсәтеп үтелде. 1989 елның декабрендә бу мәсьәләгә багышлап гомумколхоз партия җыелышы һәм партком утырышы, агымдагы елның январенда авыл Советының сессиясе үткәрелгән, агитколлективлар белән киңәшмәләр уздырылган. Агитаторлар сайлау турында яңа Законны аңлату, депутатлыкка кандидатларның биографияләре белән таныштыру һәм башка мәсьәләләр буенча агитация-масса эше алып баралар. Урта Камышлы авыл Советы буенча 15 округтан 15 кандидат, район Советына ике округтан өч кандидат күрсәтелгән.

Шулар белән беррәттән, оештыру һәм масса-политик эштә җитди кимчелекләр яшәп килә-әле. Партком, бригада партбюролары КПСС Үзәк Комитетының совет халкына Мөрәҗәгатен аңлатуга тиешле әһәмият бирмиләр. Сайлауларда республика һәм район партия оешмасының платформалары хезмәт коллективларында тикшерелмәгән. Бу мәсьәләгә багышлап стена газетасының бер номеры да чыгарылмаган. Лекция пропагандасы канәгатьләнерлек алып барылмый, партия, комсомол һәм экономик белемнәр системасы мөмкинлекләре йомшак файдаланыла. Кандидатларның ышанычлыларын укыту формасы гадәткә кертелмәгән.

Бюро утырышында бу мәсьәлә буенча колхоз парткомы секретаре В.С. Ефремов, Урта Камышлы авыл Советы председателе М. В. Кульметьев, колхоз председателе В.И. Гаврилов һәм башка иптәшләр чыгыш ясадылар.

Бу мәсьәлә буенча кабул ителгән карарда иптәш В. С. Ефремовка, М. В. Кульметьевка булган кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар күрү, сайлаучыларга КПСС Үзәк Комитеты Мөрәҗәгатен, өлкә һәм район партия оешмаларының сайлау алды платформаларын җиткерү, җәмәгать оешмаларының игътибарын бу максатка туплау, торак урыны буенча эш системасын яңадан үзгәртеп кору йөкләтелде.

Бюрода сайлауларга хәзерлек буенча район службаларының җитәкчеләре: халык депутатларының район Советы башкарма комитеты секретаре Т. А. Назарова, Чистай ЭТУСының цех начальнигы Х. К. Галиев, райпо председателе урынбасары Һ. Х. Садыйков, шәһәр электр челтәре һәм «Агропромэнерго» начальниклары Ә. И. Камалетдинов һәм А. Н. Румянцев, район финанс бүлеге мөдире Р. Г. Билалов, АТП начальнигы И. М. Вәлиев, район эчке эшләр бүлеге начальнигы В. В. Иванов, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары А. И. Газизуллин, район Советы башкарма комитетының культура бүлеге мөдире Р. К. Морадыймов, кино челтәре директоры Р.М. Низамов, КПСС райкомының партия-оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге мөдире Ф. Ш. Галимов иптәшләрнең информацияләрен тыңлады һәм игътибарга алды.

Бюрода көнкүреш хезмәте күрсәтү район производство идарәсеннән Л. А. Иванованың персональ эше каралды. Бюро учет карточкасына язып каты шелтә бирү турында башлангыч партия оешма карарын көчендә калдырды.

КПСС райкомы бюросы утырышында колхозлар һәм совхозлар, шәһәр предприятиеләре арасында социалистик ярыш йомгаклары һәм башка кайбер мәсьәләләр дә каралды.

## Конкурска йомгак ясалды

**Үткән ел, газета укучыларга билгеле булганча, «Кемнең йорты яхшырак?». Бөтенсоюз конкурсы игълан ителгән иде. Анда үз йортларыннан, хәзерләүләр конторасы белән килешү нигезендә, елга кимендә 5 мең сумлык, шул исәптән 500 килограмм ит һәм яшелчә сатучы гаиләләр катнаштырыла иде. Күптән түгел ВЛКСМ өлкә комитеты секретариаты һәм потребительләр җәмгыяте союзы идарәсе бу конкурска йомгак ясады.**

**Ярышта ВЛКСМның Октябрь район комсомол оешмасы җиңүче дип табылды. Яшь гаиләләрне йорт яны хуҗалыкларыннан продукция сатуга массовый катнаштыруга ирешкән район комсомол оешмасына ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм Центросоюзның Мактау дипломы, видеомагнитофон тапшырыла.**

**Индивидуаль ярышта икенче урынга үткән ел йорт яны участогыннан хәзерләүләр оешмаларына 9738 сумлык, шул исәптән 800 килограмм ит саткан якташыбыз— Яңа Иглайдан Ф. И. Фәйзуллин гаиләсе лаек табылды. Гаиләгә Почет дипломы, бушлай туристик путевка тапшырыла һәм чиратсыз «Урал» мотоциклы сатып алу мөмкинлеге тудырыла. Шул ук авылдан С. З. Бикиев гаиләсе өченче урынны яулады, Почет дипломына, 200 сумлык бүләккә, чиратсыз «Урал» мотоциклы алу хокукына лаек булды.**

**Бу конкурс быел да дәвам итә. Анда һәр яшь гаилә катнаша ала. Конкурс шартлары турында мәгълүматларны ВЛКСМ райкомыннан белешергә мөмкин.**

**Р. ХӘСӘНШИН.**

## ЧАКЫРУ БИЛЕТЫ

**ХӨРМӘТЛЕ НОРЛАТЛЫЛАР ҺӘМ ШӘҺӘР КУНАКЛАРЫ!**

**Сезне «Кышны озату» бәйрәменә чакырабыз. Ул 9 мартта иртәнге 10 сәгатьтә шәһәр стадионында ачыла. Ә шушы көнне иртәнге 8 дән шәһәрнең сәүдә мәйданында район колхозлары һәм совхозлары авыл хуҗалыгы продуктлары белән сәүдә итәчәкләр.**

**СЕЗНЕ БУ КӨННЕ:**

**Киң күләмдә пешкән әйберләр, кайнап торган самовардан кайнар чәй, коймак, шашлык һәм башка ризыклар көтә.**

**Мәйданда бию, төрле уеннар, аттракционнар, уен-көлке;**

**Күңелле бәйрәм концерты;**

**Җитезләр һәм кыюлар өчен спорт уеннары оештырылачак.**

**Яшь йөрәклеләр өчен түбәндәге программа: биек аякта йөрү, капчык киеп йөгерү, бау тарту, атларда чабу, китап аукционы.**

**Район тормышында беренче тапкыр булачак, сез спорт-әйбер лотереясына «Москвич» автомобиле, суыткыч, авыл хуҗалыгы лотереясына дуңгыз балалары, сарыклар, бозаулар ота алачаксыз. Билетларны райпо һәм ОРСларның барлык кибетләрендә сатып алырга була.**

**Мәйданда массовиклар, мәзәкчеләр, нидачылар эшләячәк.**

**Без көлергә, шаярырга яратучыларны бирегә чакырабыз.**

**АШЫГЫГЫЗ! АШЫГЫГЫЗ! АШЫГЫГЫЗ!**

## Намуслы хезмәттә



Таныш булыгыз: шәһәр электр челтәренең алдынгы эшчеләре Рәшит Ибраһимович Гайнуллин һәм Идрис Вәлиевич Гатин. Рәшит Ибраһимович —электрик, халыктан кергән заявкаларны вакытында үтәү, электр линияләренә хезмәт күрсәтү кебек вазифасына кергән хезмәтләрне һәрчак тиз һәм сыйфатлы башкара. Тракторчы Идрис Вәлиевич та коллективта икенче елын гына эшләсә дә тәҗрибә, башкару осталыгына ия, шуның өстенә намуслы эшче булуын раслап өлгерде инде.

Л. Шәмсуаров фотосы.

**СССР МИНИСТРЛАР СОВЕТЫНДА**

СССР Министрлар Советы ял көнен 1990 елның 11 март якшәмбесеннән җомга көнгә—9 мартка күчерергә карар итте.

Язгы көннең дәррәү
булып
Күтәрелгән чаклары
Менә-менә кабыныр төсле
Боз өсте учаклары.

Учаклар озата китәр
Кыш малае—бозларны
Уттан түгел, яздан бугай
Чәчәк кебек алсуланган
Бит алмасы кызларның.

С. Казакова фотоэтюды.



# Касыйм Исмәгыйлевич ИДРИСОВ

1990 елның 23 февралендә 77 яшендә республика билгеләмәсендәге персональ пенсионер, РСФСРның атказанган зоотехнигы, 1946 елдан КПСС члены Касыйм Исмәгыйль улы Идрисов вафат булды.

Касыйм Исмәгыйлевич хезмәт юлын 1936 елда Казан зооветеринария институтын тәмамлагач Көнбатыш Себер краенда район җир бүлегенең өлкән зоотехнигы булып башлый.

1939 елдан К. И. Идрисов, Кызыл Армия сафларында хезмәт иткәннән соң, 1941 елның октябренә кадәр Татарстан АССРның 1 нче Май» районының җир бүлегендә өлкән зоотехник булып эшли.

Касыйм Исмәгыйлевич Бөек Ватан сугышында катнаша, кавалерия полкының взвод командиры була. Җитди яра алганнан соң инвалидлыкка чыга. Ул 1943 елдан үзенең хезмәт эшчәнлеген дәвам иттерә.

К. И. Идрисов 1944 елдан башлап Октябрь районында эшли һәм үзенең 25 ел хезмәт эшчәнлеген шунда бирә. 17 ел Октябрь районы башкарма комитетының район авыл хуҗалыгы бүлегендә баш зоотехник булып эшли.

1961 елдан 1969 елга кадәр, лаеклы ялга киткәнче, «Дружба» (хәзерге Хафизов исемендәге колхоз) колхозында баш зоотехник була. Касыйм Исмәгыйлевич үз гомерен терлекчелекне үстерүгә бирә, югары квалификацияле белгеч булып җитешә. Ул тормышындагы иң мөһим эш итеп хезмәтне ала, иптәшләре аның эшлеклелек сыйфатларын югары бәялиләр, ул кешеләрне үзенә җәлеп итә белде.

Иптәш К. И. Идрисов тормышны, хезмәтне яратуы, тыйнаклыгы, таләпчәнлеге, принципиальлеге белән аерылып торды.

К. И. Идрисовның батырлыгы һәм хезмәтләре Ватаныбызның югары бүләкләре белән билгеләп үтелде. Ул Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, «Батырлык өчен» һәм башка бик күп медальләргә лаек булды.

К. И. Идрисов актив тормыш позициясендәге кеше иде. Үзенең соңгы көненә кадәр коллектив белән элемтәне өзмәде, яшьләрнең киңәшчесе һәм остазы булды.

Кеше, коммунист, тыйнак иптәш К. И. Идрисов турындагы истәлек безнең йөрәкләрдә озак сакланыр.

Х. Х. Морадыймов, Ә. В. Мөлеков, А. А. Коростелев, В. В. Богатиков, Ф. М. Галимов, Ф. Ш. Галимов, В. В. Иванов, Л. Н. Газизуллина, В. Ю. Полуян, Х. Х. Гатин, А. И. Газизуллин, Г. Ш. Нургалиев, Т.А.Назарова, М. М. Хуҗин, А. Г. Ишкинеев, Х. Н. Атауллин, Л. С. Алексеева, Т. Н. Васильева, И. И. Петров, Г. К. Гыйматдинов, В. В. Казаков, И. И. Мөхәммәтҗанов, М. И. Җәлалов, В. Х. Шәйхетдинов.

## Соңгы көннәр почтасыннан

### Яшә, авылым

Югары Норлат авылы культура йортына халык агыла. Бүген анда кичә булачак, укучы балалар һәм авыл яшьләре концерт күрсәтәчәк. Бу хәбәрне халык иртәдән үк ишеткән иде инде. Шуңа да кичке эңгер-меңгер башлану белән, авыл урамнары шат авазлар белән тулды.

Авылыбызда талантлар юк түгел бит. Концертның иң элек нәниләр башлады. Алар биеделәр, җырладылар, шигырьләр сөйләделәр. Кечкенәләрне олылар алмаштырды. Миләүшә Төхфәтуллина җырлавы һәркемгә ошады. Шуңа да аны сәхнәгә кат-кат чыгардылар. Аның гармунчысы да Ринат Мифтахов бик оста шул.

Бу кичне концертның көзгесе Рамил Хаҗиморатов булды. Тәбәнәк буйлы, бик шаян һәм тапкыр бу егетне халык үз итте. Ул гармунда уйный, өздереп җырлый, биюче егетләргә көч бирергә дә онытмый: аратирә сызгырып күңелләрен күтәреп тора. Аны карап утырган олы яшьтәге апа-абыйларның күзләренә яшь килде. Шулай булмый ни, аның әтисе Шамил Хаҗиморатов дөньядан бик яшьли китте. Ә Рамил ул үлгәндә берничә көнлек сабый иде. Ә хәзер, күрегез, әнисенә булышчы булып үсеп килә.

Бу концертны карагач, шуны әйтәсе килә: авылыбызның киләчәге якты, өметле, ышанычлы. Культура йорты пыскып янмыйча, дөрләп торачак. Болай булса, яшәячәк авылым.

**М. САБИРОВА.**

### Радио сөйләми

«Төрнәс» совхозының беренче бригадасы халкы айдан артык инде радио тыңларга тилмерә. Кайдадыр линия өзелгән, ә шуны ялгап куючы юк. Үзебезнең почта бүлегенә хәбәр иттек, файдасы булмады.

Элегрәк «Төрнәс» совхозында монтер Владимир Чудаков эшли иде. Хәзер ул авырый, аның эшен башкаручы юк. Ә менә Мамык радиоузелы моның белән нигә кызыксынмый икән? Радио өчен ай саен акча түләтәләр, аның эшләве белән кызыксынмыйлар.

Түләү зур түгел, ә менә эшләмәве кәефне боза.

**Г. ФӘТХЕТДИНОВ.**
«Төрнәс» совхозының 1 нче бригадасы.

### Әллә «Морж»лар клубы ачаргамы?

Без, Куйбышев урамының 94 а һәм 96 а йортларында яшәүчеләр, сиңа мөрәҗәгать итәргә булдык, «Чемет» дус. Хәл шуннан гыйбарәт, ягу сезоны башланганнан бирле, без өч тапкыр зур салкыннар кичердек. Безнең өйләр ягылмады. Өйләргә җылы бирүче хәзерләүләр конторасы котельнясында ягулык булмауга сылтадылар бу хәлне. Ни өчендер, аларның ягулыклары нәкъ ял көннәрендә бетә дә куя. Кемдер хәзерләүләр конторасы директоры һәм аның хезмәткәрләре җылылык белән тәэмин итүдә өзеклекне сизмәсеннәр дип шулай эшлиме икән әллә? Соңгы тапкыр 17 февральдән алып 19 ына кадәр балалар белән ягылмаган өйләрдә утырдык. Фатирлардагы җылылык алты градустан артмады.

Шәһәребездә «Морж»лар клубы юклыгы кызганыч, билгеле. Булса, безнең кебекләргә анда йөрүе бер дә читен булмас иде. Чөнки бит безнең салкынга чыныгуыбыз җиткән дип исәплибез. Озакламый яз җитә. Узган еллар тәҗрибәсе буенча, безнең фатирларда җылылык бирү туктатылачак. Ул ел саен башка микрорайоннардагыга караганда иртәрәк туктый.

«Чемет» дус! Бәлки, син безгә булышырсың.

**Ихтирам белән укучыларың: Кавкаевлар, Колмөхәммәтовлар һәм тагын 11 имза.**

ГАЗЕТАДА БАСЫЛМАСА ДА...

## Сыйфат һәм тагын бер кат сыйфат

Норлат-Октябрь райпосы азык комбинатында эшләнгән колбасаларның сыйфатсызлыгыннан зарланган хатлар редакциягә әледән-әле кереп тора. Бүген газета укучыларны шуларның тагын берсе белән таныштырабыз.

«Азык комбинаты кайчан сасыган колбаса чыгарудан туктар икән? Ә бит эшче көнозын эшләсә дә, аның 1 килограмм бәясе кадәр акча алмый. Җитәкчеләребез әлеге колбасаны ашыйлармы икән? Әгәр ашамасалар, авыз итеп карасыннар иде бер. Санитария-эпидемиология станциясе хезмәткәрләре нәрсә карыйлар икән?

Минемчә, колбаса цехы мастеры иптәш Мусатовага Чаллы Башы комбинатына барып өйрәнергә кирәктер колбаса ясарга»,—дип яза Норлат шәһәреннән иптәш Галимов.

Хат тикшереп җавап бирү өчен азык комбинаты директоры В. Ә. Ибраһимовка юлланган иде. Менә аның җавабы:

«Дөрес, 1989 елда сыйдатсыз продукция чыгару очраклары булды. Чөнки итне хәзерләүләр конторасыннан алабыз. Кагыйдә буларак, ветеринария белешмәсе һәм клеймә булса да, ит җилләнгән, кипшенгән була. Безгә килгән ит суыткычта, тиешле температурада саклана. Сыйфатсыз продукция җитештергәне өчен колбаса цехы коллективы эше киңәшмәдә тикшерелде, гаепleләр җәза алды. Продукцияне санэпидстанция, лаборатория контрольдә тота, сатучыларга продукцияне җибәрү алдыннан сыйфат таныклыгы, ГОСТ таләпләренә җавап бирүе һәм анализдан соң сәүдәгә җибәрү өчен рөхсәт кәгазе бирелә.

Колбаса заявкалар буенча эшләнә, икенче көнне үк сәүдәгә чыгарыла, сату срогы күрсәтелә. Ә менә ике көндә сатылып бетәргә тиешле колбаса кибеттә 5—7 көн ята. Аны сатуга көн саен алсаң да була бит.

Хатта күрсәтелгәннәрне искә алып, продукциянең сыйфатын яхшырту буенча чаралар планы эшләдек.

Азык комбинаты коллективы продукциянең сыйфатын яхшырту өчен бар тырышлыгын куячак.

**В. ИБРАҺИМОВ,**
азык комбинаты директоры».


## БЕЛДЕРҮЛӘР

**Норлат-Октябрь шикәр заводына даими эшкә кочегар кирәк. Уртача хезмәт хакы 250 сум. Ике ел эчендә торак белән тәэмин ителә.**

x x x

**Октябрь урман промышленносте ОРСына даими эшкә тиз арада каравылчылар һәм Чулпан авылы кибетенә сатучы кирәк. Түләү штат расписаниесе нигезендә.**

**Белешмәләр өчен Норлатта урман промышленносте ОРСына 2—16—17 һәм Заречныйдагы ОРС конторасына 3—04—04 телефоны буенча мөрәҗәгать итәргә.**

* * *

**Урман промышленносте хуҗалыгы конторасының Норлат шәһәренә күчүе сәбәпле, баш бухгалтер кирәк. Айлык хезмәт хакы 180 сум, премияләр өстәлә.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**



РЕДАКТОР Ә. У. АБДУЛЛИН.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000. Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: редактор—2—12—14, 2—22—81, редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь—2—10—44, рус теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—15—63, агропромышленность бүлеге—2—22—51, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания Хәйретдинова җыйды. Асия Моратханова верстка ясады. Наталья Закирова басты. Корректор—Зөлфия Вәлиева.

Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТАССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 27. Тираж 3.877.